وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# Дин вә Мәгыйшәт

№18 (135). 4 май 2012 / 13-җөмәдел-ахир-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ




Ачуланма ▷2◁



Мәккәгә – Истанбул аша ▷2-3◁



Бәхет юлы ▷4◁


## ЯҢАЛЫКЛАР

**МӨСЕЛМАН ЯШЬЛӘРЕ ФЕСТИВАЛЕНӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!**

Традициягә әйләнгән һәм төрле төбәкләрдә яшәүче яшьләр көтеп ала торган Мөселман яшьләре фестивале быел 25 июньнән 1 июльгә кадәр Казан янындагы "Идел" лагеренда узачак. Анда төрле төбәкләрдән җыелган ике йөздән артык яшь мөселман катнашыр, дип көтелә. Шуларның йөз алтмышы - Татарстаннан, сиксәне - илебезнең төрле төбәкләреннән киләчәк.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең яшьләр белән эшләү бүлеге "Идел" үзәге белән берлектә фестивальгә мөселман яшьләрен җыю белән шөгыльләнәчәк. Чарага имамнар һәм Казанның дини уку йортлары мөгаллимнәрен чакыру көтелә.

**МАМАДЫШ РАЙОНЫ ҮЗӘГЕНДӘ ЯҢА МӘЧЕТ ТӨЗЕЛӘ**

Мамадыш районы үзәгендә яңа мәчет төзелә. Бөек Ватан сугышы каһарманнарына куелган һәйкәл янында мәчет салыначак урын билгеләнде. Биредә Җәмигъ мәчеткә йөрүче картлар тәкъбир әйтте.

Мәчет Мамадышта туып-үскән, бүгенге көндә Мәскәүдә яшәүче эшмәкәр Роберт Хаҗиев инициативасы белән салына.

**БӨГЕЛМӘДӘ ХӘЙРИЯ АКЦИЯСЕ УЗДЫ**

27 апрельдә Бөгелмә шәһәренең Җәмигъ мәчетендә "Коръән бүләк ит!" хәйрия акциясе үтте. Әлеге чара ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан игълан ителгән Коръән елы кысаларында оештырылды.

Акция Бөгелмә районы имам-мөхтәсибе Рөстәм хәзрәт Хәйруллин тәкъдиме белән үткәрелде. Теләге булган һәр кеше Изге Китапның гарәпчәсен генә түгел, татар һәм рус телләрендә дөнья күргән тәфсирләрен дә булдыра алды.

**КАЙБЫЧ МӨХТӘСИБӘТЕ ИМАМНАРНЫ ЗУРЛАДЫ**

2 май көнне Кайбыч районы мөхтәсибәтендә имамнар җыелышы булып үтте, анда җирле хакимият һәм матбугат вәкилләре дә катнашты. Әлеге чарада 5-6 май көннәрендә зияратларда чистарту өмәләре уздыру буенча фикер алышу да булды. Шулай ук 9 май - Җиңү көне якынлашу уңаеннан имамнарны котладылар, хакимият тарафыннан бәйрәм өстәле әзерләнде. Лаеклы ялда булган хәзрәтләргә һәм Бөек Ватан сугышында катнашкан имамнарга бүләкләр тапшырылды.

*Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды*

**ГАЗЕТАЛАРГА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМЫЙК!**

**2012 елның II яртыеллыгы өчен "Дин вә мәгыйшәт" (язылу индексы - 16046) һәм "Умма" (83072) газеталарына язылу дәвам итә. 6 айга язылу бәясе - 118,38 сум.**

# Мөфти Илдус хәзрәт Фәизнең Оренбургта РФ Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле Михаил Бабич белән очрашуда ясаган чыгышы



*Хөрмәтле Михаил Викторович, Илья Александрович һәм хәзрәтләр! Бүгенге көндә Россия мөселманнары тормышында уңай алгарыш күзәтелә. Дәүләт һәм мөселманнар арасында үзара эшчәнлек мәйданы барлыкка килү -бик үк җиңел булмаган үсештә нигез булып тора: дәүләт мөселманнарның россиялеләргә рухи тәрбия бирүендә, традицияләргә хөрмәт һәм толерантлык булдыруда актив катнашуын тели. Мөселманнар дәүләтне дингә ышанучыларның ихтыяҗларын нәтиҗәле яклауны тәэмин иткән, аларның эшчәнлеге өчен шартларны яхшыртучы төрле программаларны тормышка ашыруда булышлык күрсәтүче партнёр итеп күрә. Әлеге үзара мөнәсәбәт - бүгенге заман, бүгенге көн таләбе.*

*Без барыбыз да закон нигезендә дин дәүләттән аерылганны яхшы беләбез. Әмма җәмгыять диннән башка яши алмый, шуңа күрә бу бүленеш формаль төсмергә генә ия. Дәүләт тә, дин әһелләре дә бер-берсенә мохтаҗ. Ни өчен? Чөнки гасырлар дәвамында формалашкан дини-рухи кыйммәтләр бүгенге җәмгыятьнең бик күп проблемаларын хәл итәргә сәләтле. Нәкъ менә рухи кыйммәтләр аерым кешеләргә дә, тулы бер дәүләт өчен дә үзенә күрә бер иммунитет булып тора.*

*2011 елның 11 февралендә Уфада узган Дәүләт советы утырышында Дмитрий Медведев милләтара һәм динара диалогның мөһимлеген ассызыклап: "Бу эшчәнлек яңа дәрәҗәгә күтәрелде, конфликтларны булдырмас өчен төбәкләрдә төрле конфессия вәкилләреннән торган эшче төркемнәр оештыру дөрес булыр иде", - дигән сүзләрен җиткергән иде.*

*Шул ук көнне Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов дини оешмалар белән эшләүче идарә булдыру турында Указ чыгарды. ТР Президентының дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек идарәсе хәзер республикада конфессияара татулыкны ныгыту, дини экстремизм таралуны кисәтү буенча эш алып бара.*

*Берсүзсез, дәүләт һәм дин әһелләре арасындагы диалог тыныч яшәүнең бер нигезе булып тора. Россия күпмилләтле, күпдинле дәүләт, гәрчә кайберәүләр моны танырга теләмәсә дә. Төрле милләтләр һәм төрле дин тотучылар тату яши торган Татарстан бу уңайдан бер үрнәк мисал. Татарстан толерант исламны пропагандалый. Һәм моның өчен күп тырышлык куя. Республика җитәкчелеге халыкны яклауга, радикаль агымнардан саклауга кагылышлы дәүләт сәясәтен тормышка ашыруга барлык шартларны тудыра.*

*Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте төрле дәүләт структуралары белән актив эшли. Узган ел дәүләт органнары белән үзара эшчәнлек алып бару турында төзелгән килешүләр шуны раслый. Наркотикларга бәйлелеккә төшкәннәрне социаль һәм рухи-әхлакый тернәкләндерүгә юнәлтелгән шундый килешүләрнең берсе РФ Наркотиклар әйләнешенә күзәтчелек итүче федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсе белән төзелде. РФ Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе белән төзелгән килешүне дә әйтеп үтәргә кирәк. Әлеге килешү нигезендә ике як та тоткыннарга, җәзаларны үтәтү федераль хезмәте системасы хезмәткәрләренә, шулай ук аларның гаилә әгъзаларына рухи-әхлакый тәрбия һәм дини белем бирү җаваплылыгын үз өсләренә алды.*

*Болардан тыш, Диния нәзарәте бүтән дәүләт структуралары проектларын тормышка ашырырга да булышлык итә: ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан булдырылган балалар хосписы; РФ Эчке эшләр министрлыгының "Эчке эшләр органнарында хезмәт итү. Рухилык, мораль, закон" проекты һәм башкалар…*

*Хөрмәтле Михаил Викторович һәм башка катнашучылар!*


*Тагын бер тапкыр игътибарны шуңа юнәлтәсем килә: Россия - бу җирдә яшәүче мөселманнарның Ватаны. Россия Исламына көнбатыштагы кебек 50 генә түгел, меңнән артык ел. Бу факторны Россиянең эчке сәясәтендә исәпкә алу мөһим. Милләтара һәм динара мөнәсәбәтләрне җайлау юлыннан барган бүгенге заман Россия өчен дәүләтнең, мөселманлыкның тарихи тәҗрибәсен, мәдәни мирасын һәм идеяләр традициясен исәпкә алу бик тә әһәмиятле. Игътибарыгыз өчен рәхмәт!*

# ҮРНӘК ВӘГАЗЬЛӘР КИТАБЫ ДӨНЬЯ КҮРДЕ

**Нияз САБИРОВ турында белешмә.**

***Казанда туып үскән. Дини гаиләдә тәрбияләнгән. Атаклы Габделхак хәзрәт Каюмов, Габделхак хәзрәт Саматов кебек остазлардан дини белем алган.***

Башкалабызның 52 нче мәктәбен, КДУ каршындагы лицейны, Казан дәүләт педагогика университетын тәмамлый. 2006 елда ТР Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтына аспирантурага керә. Сәясәт фәннәре докторы Рәфыйк Мөхәммәтшин җитәкчелегендә "XVII-XVIII гасырлар татар иҗтимагый фикере үсешенә суфичылык традицияләренең йогынтысы" дигән темага диссертация әзерли. 2007 елдан Россия ислам университетында "Татар халкының рухи мирасы" курсларын алып бара. 2009 елда Казан шәһәре имам-мөхтәсибе Мансур хәзрәт Җәләлетдинов чакыруы буенча Казан ислам көллиятендә дә дәресләр алып бара башлый.



Күптән түгел генә ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы әгъзасы, Казан ислам көллиятенең директоры урынбасары Нияз Сабировның "Чакыру" исемле китабы (Казан: Милләт, 2012. - 184 б.) табадан төште. Әлеге китапта 26 үрнәк вәгазь урын алган. Шул уңайдан, Нияз хәзрәттән кыска гына интервью алырга булдык.

**- Аңлавымча, бу сезнең тәүге китабыгыз. Кыскача гына аның басылу тарихына тукталып үтсәгез иде...**

- Мин 2010 елда мөфтиятнең Голәмәләр шурасына әгъза итеп билгеләндем. Һәм шул шура тарафыннан миңа татар телендә үрнәк вәгазьләр язу бурычы йөкләтелде. Шуннан соң барлык укылган вәгазьләремне бер төшкә тупларга керештем (ул Казанның Мәрҗани мәчетендә җомга намазлары алып бара. - ред.). Алар Голәмәләр шурасы утырышында каралды һәм нәшер итәргә тәкъдим ителде. Шунысын да ассызыклап узасым килә: бу китапта тирән дини мәсьәләләр яктыртылмый, ул дингә яңа гына аяк басып килүчеләргә тәкъдим ителә. Китап шулай ук имамнар өчен дә зур ярдәмлек булыр дип ышанабыз.

**- Китапка вәгазьләр темасы ни рәвешле сайланды?**

- Монда мөбарәк кичәләр, тәүбә-истигъфарлар хакындагы, пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв), хәнәфи мәзһәбенең әһәмияте, әдәп-әхлак турындагы вәгазьләр урын алды. Белүебезчә, динебез өч өлештән тора: иман, ислам, әхлак. Китапта шул өч өлешнең һәркайсына караган вәгазьләр бар.

**- Ә ни өчен исемен "Чакыру" дип куярга булдыгыз?**

- Хәзерге вакытта, әлхәмдүлилләһ, мәчет-мәдрәсәләребез уңышлы гына эшләп килә, динебез үсә. Ләкин мәчеткә йөрмәүчеләр дә аз түгел. Аларны гыйбадәтханәләргә вәгазьләр тыңларга, намаз укырга өйрәнергә чакырабыз. Китапка тикмәгә генә эпиграф итеп Җәләледдин Руминың шигыреннән өзек китермәдек:

***Кил, кил, кем булсаң да, кил,***
***гәрчә кяфер йә утка табынучы,***
***яисә потка табынучы***
***булсаң да, кил,***
***безнең рухи мәктәп өметсез түгел,***
***йөз тәүбәне бозган булсаң да, кил.***

Мәчет ишекләре ул барлык кешеләр өчен дә, шул исәптән, башка конфессия вәкилләре өчен дә һәрвакыт ачык. "Мин әле әзер түгел", "Мин әле гөнаһлы гамәлләр кылам" дип мәчеткә килүне кичектереп йөрергә ярамый.

**- Киләчәккә нинди планнарыгыз бар? Мондый төрдәге китаплар тагын дөнья күрәчәкме?**

- Монда ярты ел дәвамында укырга мөмкин булган җомга вәгазьләре урын алды. Ниятебез - шуның икенче кисәген әзерләп бастыру. Икенче кисәктә, иншә Аллаһ, Коръән сүрәләренең тәфсирен, сәхабәләрнең, бөек галимнәребезнең тормышыннан мисаллар китерүне максат итеп куябыз.

**- Ә бу "Чакыру" китабын кайдан алырга мөмкин?**

- Ул Шәехҗан Фәния Хуҗахмәт мөхәррирлегендә дөнья күрде. Китапны күпләп алырга теләүчеләр түбәндәге адрес буенча мөрәҗәгать итә ала: Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 57 нче йорт (ишегалдыннан керәсе), 5 нче офис. Тел.: **8 (843) 253-43-08.**

**Газета укучыларыбыз игътибарына яңа китаптан бер вәгазь тәкъдим итәбез. (2 нче битне карагыз.)**



# АЧУЛАНМА

**Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-ражииим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһи раббил гааләмииин вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил кәрим үә галәә әәлиһи үә әсхабиһи әҗмәгыйн.**

Бөтен галәмнәрнең Раббысы, тәрбиячесе булган, безгә яшәү мәгънәсен аңлатучы Коръәнне бүләк иткән Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләгә барча хәмед-сәнә, шөкераналарыбыз булса иде. Безнең өчен иң күркәм үрнәк булган нурлы Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле әһленә, сәхабәләренә, күңел түрләребездән чыккан сәламнәребез, салаватларыбыз һәм һәртөрле изге догаларыбыз булса иде.

Газиз дин кардәшләрем, әссәләәмегаләйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәтүһү! Бүгенге вәгазебез тискәре сыйфат - ачу турында булачак.

Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнең иң якын сәхабәләрнең берсе булган Әбү Һөрәйрә (Аллаһ аннан разый булсын) риваять иткәнчә, бер кеше Пәйгамбәр галәйһиссәләмнән: "Миңа киңәш бирче", - дип сораган. Аллаһның расүле галәйһиссәләм: "Ачуланма!" - дигән. Шуннан соң теге кеше үзенең үтенечен берничә тапкыр кабатлаган, ләкин Пәйгамбәребез галәйһиссәләм һаман: "Ачуланма!" - дип җавап кайтарган (Бохари).

Әлеге кеше Әбу Дәрдә булган дип риваять ителә. Ул әйтте: "Бервакыт мин: "Әй, Аллаһның илчесе, миңа җәннәткә керергә ярдәм итәчәк эшне күрсәтсәнә", - дидем. Ул: "Ачуланма, һәм җәннәтле булырсың", - дип җавап бирде (Имам Табарани).

Һәр көнне кем белән булса да аралашабыз, сөйләшәбез, кайвакыт кемдер үзенең сүзләре яисә гамәлләре белән ачуыбызны чыгарырга мөмкин. Шундый вакытларда хак мөселман хәдистә әйтелгәнчә, ачуын йотарга, ачу утын сүндерергә тырышырга тиеш, чөнки ачу кешене башка гөнаһлы гамәлләргә этәрергә мөмкин. Кеше ачуланып үзенә генә түгел, башкаларга да зыян китерә.

Галимнәребез ачудан котылу өчен берничә юл тәкъдим итәләр:

1) Шәйтан вәсвәсәсеннән Аллаһы Тәгаләгә сыгыну.

Бер көнне берәү Пәйгамбәребез галәйһиссәләм янында ачуланган вакытта Аллаһның расүле галәйһиссәләм үзенең сәхабәләренә әйткән: "Мин шундый сүзләрне беләм, әгәр аларны теге кеше әйтсә, ачу китәчәк: Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-ражииим. Имам Маварди (Аллаһның рәхмәтендә булсын) үзенең "Әдәб әд-дөнья вә әд-дин" дигән китабында әйткән: "Ачу вакытында Аллаһны искә алырга кирәк. Шул вакытта кеше Аллаһтан курка башлар һәм ачуын эчтә калдыра алыр. Бөек Аллаһ изге Коръәндә болай дип әйтә: "Аллаһны оныткан вакытта, Аны искә алыгыз" ("Кәһеф (Мәгарә)" сүрәсе, 24 нче аять).

2) Дәшмичә тору.

Ачуыбыз килгәндә, үзебезгә һәм башкаларга зыян китермәс өчен, бернәрсә дә әйтмәскә тырышырга кирәк. Сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәләм бу турыда әйткән: "Әгәр берәрегез ачуланса, эндәшмәсен", - дигән (Әхмәд бин Хәнбәл, Тирмизи).

3) Гәүдә торышын үзгәртү.

Пәйгамбәребез: "Берәрегез басып торганда ачуланса, утырсын; ачуы басылмаса, ятсын", - дип әйткән (Әхмәд бин Хәнбәл, Әбу Давыд).

4) Тәһарәт алу.

Аллаһның расүле Мөхәммәд галәйһиссәләм: "Дөреслектә, ачу - шәйтаннан. Ә шәйтан уттан яралтылган. Берәрегезнең ачуы чыкса, тәһарәт алсын", - дип әткән (Әхмәд бин Хәнбәл, Әбу Давыд).

5) Ачуланган вакытта үз ачуын йота алган кеше зур әҗер вә савапларга ирешә. Шуны һәрвакыт истә тоту.

Аллаһ Раббыбыз хак мөселманнарны мактап, Коръәндә болай дип әйтә: "Ул мөэминнәр бай чакларында да, ярлы чакларында да Аллаһ күрсәткән урыннарга сәдака бирәләр, ачулары килгәндә ачуны йоталар, гаепле кешеләр гафу сораганда гафу итәләр. Яхшылык кылучы әнә шундый мөэминнәрне Аллаһ сөядер" ("әл-Гыймран (Гыймранның гаиләсе)" сүрәсе, 134 нче аять).

6) Хак көч - физик көч түгел, ә рухи көч.

Аллаһның расүле галәйһиссәләм әйткән: "Сугышта үз дошманнарын җиңгән кеше чын батыр булмас, ә ачу килгәндә ачуын йота алган кеше чын батыр булыр", - дигән (Бохари).

7) Аллаһның расүле Мөхәммәд галәйһиссәләмнең күркәм әхлагын һәрвакыт истә тоту.

Искә төшерик әле, мөхтәрәм җәмәгать! Пәйгамбәребез галәйһиссәләм, үзенә пәйгамбәрлек иңгәннән соң, ун ел Мәккә шәһәрендә кешеләрне иманга чакырды, ләкин иманга килүчеләрнең саны гаять дәрәҗәдә аз иде. Аны рәнҗеттеләр, төрле авыр сүзләр әйттеләр. Шулар өстәвенә, пәйгамбәрлекнең 10 нчы елында, Пәйгамбәребез галәйһиссәләмне тәрбияләп үстергән, аңа таяныч булган агасы Әбу Талиб үлеп китте. Аңа терәк, таяныч булган хатыны Хәдичә (Аллаһ аннан разый булсын) вафат булды, шуңа күрә пәйгамбәрлекнең унынчы елын - кайгы елы дип атадылар. Шуннан соң да Пәйгамбәребез галәйһиссәләмгә бик күп авырлыклар күрергә туры килде. Аллаһның расүле галәйһиссәләм Мәккә шәһәрендәге кешеләрне иманга өнди-өнди гаҗиз булгач, кешеләрне дингә чакырыр өчен Зәед бин Харис (Алла аннан разый булса иде) исемле сәхабәсе белән Мәккәдәнерактарак булган Таиф шәһәренә барды. Анда да аны бик начар каршыладылар, ташлар атып, куып җибәрделәр. Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнең аяклары ярылып, канап бетте. Шәһәрдән чыккач, Пәйгамбәребез галәйһиссәләм болай дип дога кылды: "Йә Раббым, мин үземнең көчсезлегемнән, гаҗизлегемнән Сиңа сыенам. Йә Раббым, миңа золымлык кылган кешеләрнең зарарыннан сиңа сыенам. Йә Раббым, миңа дөрес юлларны күрсәт. Әллә мин өндәгән дин дөрес түгелме? Әллә минем берәр гаебем бармы?" - дип Аллаһы Тәгаләдән сорады. Аллаһ Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнең шушы догасын ишеткәч, Җәбраил фәрештәгә ияртеп, тау фәрештәсен җибәрде. Тау фәрештәсе болай дип әйтте: Йә, Мөхәммәд, мин - тау фәрештәсе. Аллаһы Тәгалә синең янына җибәрде. Әгәр теләсәң, Таиф халкын тау астында калдырам, һәлак итәм, - диде. Пәйгамбәребез галәйһиссәләм моңа ризалык бирмәде: "Алар иманга килерләр әле, алар өметсез түгел, һәлак итмик", - дип әйтте. Бу - безгә зур үрнәк. Сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәләм шундый авыр чакта сабыр булып калды, ачуын йотты.

8) Ачуның зыянын истә тоту.

Әгәр ачуланган вакытта Аллаһ күреп һәм ишетеп торганын истә тотсак, үзебезне ничек тотар идек? Яки яныбызда сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәләм басып торса, нәрсә эшләр идек? Ачу - кешеләр сыйфаты түгел, ә хайваннар сыйфаты.

Бер көнне Гайсә галәйһиссәләм яһүдиләр яныннан үткәндә, үзенә карата әйтелгән начар сүзләр ишетте. Ул аларга изге сүз белән җавап бирде. Гайсә галәйһиссәләм янында булган кешеләр гаҗәпләнеп сорадылар: "Ничек инде син үзеңә начар сүзләр әйткән кешеләргә изге сүзләр белән җавап бирдең?" - диделәр. Гайсә галәйһиссәләм болай диде: "Һәр кеше үзендә булган нәрсәне сарыф итә".

Мөхтәрәм мөселманнар! Бер риваять сөйләп үтәм.

Начар холыклы бер егеткә әтисе бер капчык кадак бирә һәм:

- Әй, улым, ачуың килеп, яки кем белән булса да ачуланышканда бакча диварына бер кадак кагып куй, - дип әйтә.

Улы беренче көнне үк утыз җиде кадак кага, әмма көннән-көн кадак кагу күпкә кими бара, ягъни егет әкренләп ачу хисләрен тыярга өйрәнә, чөнки ул кадак кагуга караганда ачу хисләрен тыеп калуның җиңелрәк икәнен аңлый башлый. Шулай итеп, бу егет ачуын тыярга өйрәнә һәм кадак кагудан бөтенләй арына. Әтисе янына барып, шушы яңалыкны хәбәр итә. Атасы аңа:

- Әй улым, хәзер инде, киресенчә, ачуың килгәндә барып, каккан кадакларыңны берәмләп кире суырып ал, - дип әйтә. Күпмедер вакыт үткәч, егет әтисенә:

- Син кушканнарны эшләдем. Диварда бер кадак та калмады, барысын да суырып алдым, - дип әйтә. Атасы аны дивар янына алып барып:

- Улым, син, әлбәттә, сүземне үтәдең, ләкин диварда күпме тишек калганын күрәсеңме? Нәрсә генә эшләсәң дә, ул беренче халәтендәге кебек яңа булмаячак инде. Әгәр син сабыр итә алмыйча, берәрсе белән ачуланышып, аңа авыр сүзләр әйтәсең икән, бу гамәл аның йөрәгенә шул кадаклар кебек тәэсир итәчәк. Соңыннан күпме генә гафу үтенсәң дә, (кадакларны кире суырып алган кебек) әйткән сүзләрең өчен гафу үтенсәң дә, барыбер күңелендә яралары калачак. Авыр сүз белән берәрсенең күңелен яралау кайвакыт кул белән яра ясауга караганда да авыррак, шуңа күрә, улым, якыннарың, туганнарың, дусларың һәм, гомумән, кешеләр белән аралашкан вакытыңда, авыр сүз әйтер алдыннан бик нык итеп уйла син. Кадак кагу белән күрсәткән мисалны беркайчан да онытма, улым, - дип әйтә.

Пәйгамбәребез үзенең бер мәшһүр хәдисендә әйткән: "Кем Аллаһы Тәгаләгә һәм Ахирәт көненә иман китергән булса, кунагын хөрмәт итсен. Кем Аллаһы Тәгаләгә һәм Ахирәт көненә иман китергән булса, күршесенә игелек итсен. Кем Аллаһы Тәгаләгә һәм Ахирәт көненә иман китергән булса, хәерле сүз сөйләсен яисә дәшмичә торсын", - дигән (Бохари, Мөслим).

Аллаһ Раббыбыз барчабызга бары тик файдалы, кирәкле сүзләр сөйләргә, ачу килгәндә ачуны йотарга һәм сабыр булырга насыйп итсә иде.

***Фото иллюстрация рәвешендә бирелә.***
***Нияз хәзрәт САБИРОВ***

**Гасырлардан-гасырларга Истанбул изге Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләренә бару юлында Россия мөселманнары өчен йөкне күчереп төяүнең төп пунктларыннан берсе саналган. Монда Кара диңгез дулкыннарыннан талчыккан хаҗилар бераз ял итеп, чүл һәм диңгез аша озын юлны дәвам иттерү өчен көч җыя, азык-төлек һәм су хәстәрләп куя алган. Әгәр дә урта гасырларда Идел буе юлчысына Истанбулга кадәр барып җитү өчен айлар кирәк булган булса, XIX йөз ахырында техник алгарыш (поездлар, уңайлы тизйөрешле суднолар) Истанбулга кадәр юлны шактый җиңеләйткән һәм Мәккәгә кадәр баручы берничә маршрут барлыкка килгән.**

Беренче маршрут булып Мәскәү юнәлеше торган. Варшава һәм Вена шәһәрләре аша поезд белән юлчы Истанбулга кадәр алты көн эчендә барып җитә алган. Әлеге маршрут диңгез сәяхәтеннән курыккан кеше өчен бигрәк тә уңайлы булган. Бары тик билет бәясе генә шактый кыйбат - 100 сум тирәсе торган.

Икенче юнәлешне Акъяр (Севастополь) юнәлеше буларак билгеләргә мөмкин. Акъярдан Истанбулга кадәр пароход атнасына бер тапкыр йөргән, һава торышына бәйле рәвештә, сәфәр 30 сәгатьтән алып ике тәүлеккә кадәр сузылган. Әмма суднолар кечкенә булганга һәм яхшы ук искергәнгә күрә, көчле давыллы көннәрдә алар диңгездә каты чайкалган. Җитмәсә, хаҗга бару чорында пароходлар пассажирларны нормадан күпкә арттырып алганнар, шуңа күрә әлеге маршрут куркынычсыз булып саналмаган. Моннан тыш, Акъяр пароходына билет табуы да җиңел булмаган.

Батум юнәлеше Кавказ мөселманнары өчен уңайлы булган. Һава торышы уңай торганда 7-8 көндә, начар булганда 10-12 тәүлек эчендә пароход Истанбулга кадәр килеп җитә алган. Рейслар еш, ә суднолар зур булган.

Одесса маршруты белән Төркестан, Идел һәм Урал буе хаҗилары файдаланган. Ул пароходлар атнасына 5-6 тапкыр йөргән һәм соңгы тукталышка 32-34 сәгатьтә килеп җиткән. Суднолар зур үлчәмле булганлыктан һәм яхшы җиһазландырылганлыктан, пассажирларны күп сыйдырган һәм диңгездә чайкалу сизелмәгән диярлек.

Хаҗиларның төп өлеше Одессага (Адис) җыйналган. XX гасыр башында шәһәрдә берләнбер җәмигъ мәчет һәм татар мәктәбе булган. Мөселманнар Одессаның төрле почмакларында яшәгәнлектән, аерым ислам мәхәлләсе булмаган. Читтән килгән мөселманнарның проблемаларын хәл итүдә шәһәрнең хөрмәтле имамы Сабирҗан Сәфәров ярдәм күрсәткән. "Мөселман" кунакханәсе булып Касыйм татарлары тоткан "Мәскәү" кунакханәсе саналган. Одессага кадәр Төркестан хаҗилары тимер юл белән Красноводскига (хәзерге исеме - Төрекмәнбашы) кадәр килеп җиткәннәр, шуннан соң Каспий (Хәзәр) диңгезеннән - Бакыга кадәр һәм аннан соң - Ростовка һәм Одессага кадәр барганнар.

***Рухи кыйммәтләр алышынып бара торган бүгенге борчулы заманда армиядә хезмәт итү элгәре кебек бик үк дәрәҗәле саналмаса да, 18 яшен тутырган егетләргә, дәүләтнең катгый таләбе буенча, туган-тумачасы, дус- ишләре белән саубуллашып, билгеле бер вакытка ерак җирләргә чыгып китәргә туры килә. Яшерен-батырын түгел: ата-аналар юкка гына борчылмый хәзер, моның җитди сәбәпләре дә бар, әмма нишләмәк кирәк - илне дә сакламыйча булмый.***

Элек-электән Ватанга хезмәт итү изге, саваплы гамәлләрдән саналган. Ислам дине дә моның шулай булуын раслый. Чит җирләргә барып, сәфәр кылып дөнья күрү, төрле кешеләр белән аралашып гыйбрәт алу пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм тарафыннан хуплана.

Аннары шунысы да бар: егетнең хәрби хезмәткә китүе аның сәламәт, көчле булуын күрсәтә. Хезмәт итү чорында җитди сынаулар үтеп, тормыш тәҗрибәсе туплап, солдат-егет физик яктан гына түгел, рухи мәгънәдә дә ныгып кайта. Шулай ныгып, исән-имин әйләнеп кайтканнан соң ул, иншә Аллаһ, якын-

# Мәккәгә – Истанбул аша



Моннан тыш, башка юл да булган: Ташкенттан һәм Бохарадан юлчылар поезд белән Тулага кадәр килгәннәр, аннан соң Одессага кадәр баручы поездга күчеп утырганнар.

Төркия консуллыгы урнашкан Одессада хаҗилар "Истанбул аша Мәккәгә кадәр" дип язылган турист визасы алганнар. Әгәр дә белеп бетермәү яки ялгышлык сәбәпле виза бары тик Истанбулга кадәр генә бирелгән булса, анда хаҗиларны уңайсызлыклар сагалап торган: Россия илчелеген эзләп йөрү, паспортны төрек теленә күчертү, өстәмә чыгымнар һ. б.

Босфорга килеп җиткәннән соң, бугазны үтү өчен пароходлар кояш чыкканын көтәргә тиеш булганнар. Әмма көтеп тору үзүзен тулысынча аклаган: таң белән юлчыларга диңгезнең һәм шәһәрнең мәһабәт һәм могҗизаи күренешләре ачылган.

Таможняны уңышлы узган хаҗилар "хан"нарга - юлчылар кереп куна торган йортларга яки кәрвансарайларга урнашканнар. Иң чиста һәм ышанычлы булып шәһәр үзәгендәге "Ярым хан", Мәхмүд Паша районындагы "Йолдыз ханы" кебек мосафирханәләр саналган. Әгәр дә анда урын булмаса, кунакларны гел елмаеп каршы алучы зур кунакханәгә - "Шәриф Паша ханы"на, шулай ук Истанбулның зур базары - Чаршы янында урнашкан "Гадлия ханы" яки "Балтачы ханы"на урнашырга мөмкин булган.

Күп кенә хаҗилар Истанбулда якташларын тапкан: Россия мөселманнары Төркиягә һәм гарәп илләренә сәяхәт итү дәверендә шәһәрнең төрле районнарында күчемсез милек сатып алганнар яки йортлар салганнар, үзләренең якташлык җәмгыятьләрен, хәйрия оешмаларын булдырганнар. Истанбулдагы Россия ватандашларының кайбер биналары Казаннан, Кырымнан килгән ярлы шәкертләр өчен тору урыны булып хезмәт иткән. Россия мөселманнарын контрольдә тоту җиңелрәк булыр дигән ышаныч белән Россия дәүләте мондый "йорт"лар (приютлар) төзүгә үз ярдәмен күрсәтеп торган. Болай эшләгәндә, Төркиягә килгән россиялеләргә "госманлы фанатизмының" йогынтысы азрак булыр, дип өмет ителгән. Мәсәлән, Госманлы империясендәге рус илчесе Н.П. Игнатьев 1864-1877 елларда үзенең Тышкы эшләр министрлыгына язган яшерен хатында мондый төр биналар төзелеше белән чынлап торып кызыксынуын белдергән.

Истанбулда тагын "Казан" һәм "Үзбәк" тәккәләре - тәккыяләре булган: суфиларның яшәү урыны булган бу биналарга Бохарадан яки Идел буеннан күчеп килгән дин әһелләре нигез салган. Алар, нигездә, нәкышбәнди (икенче төрле - нәкшибәндия) тарикатенә караган, чөнки нәкъ менә әлеге суфи юнәлеш XX йөз башына кадәр Россиянең төрки телле мөселманнары арасында киң таралган була. XIX гасыр ахырында Истанбулда гына да илледән артык нәкышбәнди тәккыясе исәпләнгән. Аларның "Казан" һәм "Үзбәк" тәккәләре дип аталганнары Урта Азиядән һәм Идел буеннан килгән хаҗиларны үзенә сыендырган, ерак юлдан килгән юлчыга кадер-хөрмәт күрсәткән.

Нәкъ менә хаҗ юлчылыгында күпчелек очракта Россиянең дин әһелләре госманлы шәехләре белән танышкан, алар белән сөхбәттә - рухи аралашуда торган, аларның ризалыгын - иҗазәсен алып, суфичылык тәгълиматын үзләренең туган якларында таратканнар. Мисал өчен, Нур-Госмания мәчете янындагы Казан тәккыясендә төрле вакытларда Идел буе мөселманнарының танылган рухи лидерлары - Шиһабетдин Мәрҗани (1818-1889), Зәйнулла Рәсүли (1833-1917), Морад Рәмзи (1854-1934), Габдеррәшит Ибраһим (1857-1944) һәм башкаларның тукталуы билгеле.


Хаҗилар Истанбулда иң аз дигәндә бер атна торганнар һәм вакытларын юкка әрәм итмәгәннәр: сәүдә иткәннәр, мөселманнар өчен истәлекле урыннарда булганнар. Күпләр үзләренең бурычы итеп шәһәрнең күпсанлы "изге" зыярәт җирләрендә, шулай ук Айасуфия, Солтан Әхмәт, Солтан Фатих, Солтан Баязид, Нур-Госмания кебек мәчетләрдә булуны санаган. Әмма барыннан да элек, хаҗга баручылар Мөхәммәд пәйгамбәрнең аяк табаны эзен, өс киемен (хирка-и сәгадәт) һәм сәхабәләрдән (сәхабә-и кирам) калган истәлекле әйберләрне күрергә теләгән.

Россия хаҗилары шулай ук Истанбулдагы җомга вәгазьләрен дә зарыгып көтеп алган. "Хаҗилар өчен юлкүрсәткеч" китабының авторы Гали Риза (Казан, 1909) госманлы вәгыйзьләренә соклануын яшерми: "Күпчелек мәчетләрдә төшке аштан соң вәгазь укыйлар. Истанбул вәгыйзьләрен тыңламыйча китәргә һич ярамый, чөнки алар безнең Россиянекеләрдән бик нык аерыла. Истанбул вәгыйзьләре һәртөрле мактауга лаек. Аларның теле вә тавышы чиста һәм бик матур, үзләре, һичшиксез, оста сөйләү сәләтенә ия. Туктап тормыйча һәм сулышны тоткарламыйча, алар өч-дүрт сәгать дәвамында сөйли алалар, моннан тыш бар нәрсәне гади телдә аңлатып бирәләр, күпчелек тыңлаучылар өчен аңлаешсыз гарәп аңлатмаларына вакыт әрәм итмиләр. Берничә аять белән сүз башлыйлар, аның төп мәгънәсен аңлаталар, көндәлек тормыштан ачык мисаллар китерәләр, һәр мөһим фикердән соң нәтиҗә ясыйлар. Хәтта беркайчан да еламаган таш йөрәкле кешеләр дә, аларның вәгазендә ачы күз яшьләрен агызалар. Шатлыкның ни икәнлеген белеп җиткермәгән кешеләр искәрмәстән аларның вәгазе вакытында рәхәтлек һәм бәхет тойгысы эзләп тапкандай булалар", ди.

Алдынгы карашлы дин әһелләре Айасуфия, Баязид (Хәмидия), Фатих китапханәләренә, янычарларның (элекке Төркиядә аерым хокуклар белән файдаланып килгән җәяүле гаскәр) балавыз фигуралары музеена, күпләгән бассейннары, күлләре, көймәләре, машиналары булган Солтан Габделхәмитнең таң калырлык бакчасына йөргәннәр. Сәүдәгәрләр өчен чын дәрәҗәсендә музей булып, борынгы әйберләр, алтын-көмешләр, тагын әллә ниләр, әллә ниләр белән сәүдә иткән зур базар - "Чаршы кәбир" саналган.





Күпне күргән сәяхәтчеләр һәм хаҗилар Истанбулда иң ышанычлы банкның "Банка-и Госмания" икәнен абайлап алганнар, аның якындагы бүлекчәсе Галата районында урнашкан булган.

Ерак юл алдыннан тәнне юу һәм чистарыну өчен хаҗилар төрек мунчаларына - "хаммам"нарга кергәннәр, болар Россия мунчаларыннан шактый нык аерылган: агач башмаклар, мәрмәр өстәлләр һәм хәтта мунчачы-массаж ясаучылар үзләре үк сәер дә, гаҗәп тә булып тоелганнар...

Истанбул хаҗиларга шундый бөек һәм ачык булып күз алдына килеп баскан ки, шәһәрне карап чыгу өчен хәтта берничә атна да җитмәгән. Әмма алга атларга, юлны дәвам итәргә кирәк булган. Истанбулдан Мәккә һәм Мәдинә тарафына өч маршрут булган: Бәйрут белән Яфа аша - Хиҗаздан тимер юл буенча турыдан-туры Мәдинәгә кадәр; Мисыр аша Сүәеш юнәлешендә: пароход белән Йәнбүгъ белән Җиддәгә кадәр һәм аннан соң тимер юл белән барырга мөмкин булган.

Өченче маршрут исә Одессада ук Искәндәриягә баручы пароходка утыру өчен билет алганнарга уңайлы булган. Бу билет белән хаҗилар Истанбулда кирәк кадәр тукталып тора алган, ә аннан соң шушы пунктка кадәр теләсә кайсы Россия пароходына утыра алган. Мисыр юнәлешен сайлаганнар исә Истанбулда почта ташучы пароходка билет алганнар. Сәяхәтчеләр юлда Госманлы империясенең бүтән шәһәрләре - Галиболу, Чанаккальгә, Измир белән дә танышканнар. Һава торышы әйбәт торган очракта, аларны биш тәүлектән соң Мисыр каршылаган; аннары алар тимер юл буйлап Сүәешкә, шуннан соң пароход белән Җиддәгә кадәр барганнар.

Алда юлчыларны тагын күп кенә мавыктыргыч хәлләр көтеп торган. Хаҗиларның кайберләре көндәлекләр алып барган, өйләренә кайткач аларны хаҗнамә, сәяхәтнамә, ягъни юл язмалары кебек язып бастырганнар. Әлеге әсәрләр бары тик әдәбиятчылар өчен генә түгел, тарихчылар өчен дә кызыклы чыганак булып тора, чөнки еш кына аларның авторлары Россия, Төркия, Мисыр һәм Гарәбстан халыкларының тормышы һәм көнкүреше турында объектив картиналар тудыра алганнар.

***Әлфинә СИБГАТУЛЛИНА,***
***филол. ф. д., Россия фәннәр академиясенең Шәрыкны өйрәнү институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре***

# АРМИЯГӘ КИТӘ ЕГЕТЛӘР...

нарына, гаиләсенә ышанычлы, нык терәк булачак. Әмма бу - кайткач. Бүген исә без аны озатабыз. Шушы язмада нәкъ менә озату йоласына кагылышлы фикерем белән уртаклашасым килде.

Күптән түгел туганнарыбыз ашка чакырдылар:

- Улыбыз армиягә китә, шуны Коръән укытып, вәгазь тыңлатып, догалар кылып озатырга булдык...

Мәҗлес бик күркәм, эчтәлекле үтте. Аны алып барган Райнур хәзрәт Җиһаншинның Коръән укып дога кылуы, вәгазе, өлкәннәрнең нәсихәтләре булачак солдат Салават Фәләхов күңелендә фәкать изге хисләр генә уяткандыр. Һәрхәлдә, аның тормышындагы беренче ерак сәфәре "Бисмилла"дан, изге сүздән башланды. Улларын Аллаһы Тәгаләгә тапшырып олы юлга озату әтисе Илдар белән әнисе Гөлназ өчен дә, бабасы Раиф белән әбисе Асиябикә өчен дә зур юаныч булды.

- Салават Кукмара аграр көллиятендә укып, һөнәр үзләштерде. Тәртипле, эш сөючән егет. Спорт белән шөгыльләнгәч, физик яктан да ышанычлы күренә, ләкин дөнья булгач, хафаландыра шул, - ди бабасы. - Исән-сау йөрсен, әйбәт хезмәт итеп кайтсын!

- Әти-әниең, туганнарың янда булмаган ерак җирдә Аллаһы Тәгалә Үзе сиңа ярдәмче булсын, улым, - дип теләген җиткерә әбисе. - Ләкин моның өчен үзең Аны онытма, күңелеңнән чыгарма.

Сүзгә әтисенең абыйсы Рәүф кушыла:

- Бер елдан "как штык" - өйдә буласы! Ә тегендә - урталык кадерле. "Сәнәктән көрәк булырга" тырышканнарны өнәп бетермиләр анда. Дәү әбиең әйтә торган иде: "Усал булсаң - асарлар, юаш булсаң - басарлар, урта булсаң - ил агасы ясарлар". Менә шулай, энекәш...

Башка туганнарның да киңәш-теләкләрен җөпләп, Райнур хәзрәт бер бик мөһим, кирәкле сыйфатны искә төшерә:

- Һәрвакытта да сабыр булып каласы. Шәйтан кабаланып, ярсып эш иткәнне ярата, ә Аллаһы Тәгалә иплә, тыныч, хикмәт белән гамәл кылырга куша. Аллаһ разый булырлык эшләүнең файдасын тормыш инде күптән исбатлады...

Хәләл ризыклы табын алдында барган җанлы сөйләшү кызыклы да, гыйбрәтле дә булды. Шунда уйлап куйдым: мәҗлес аракылы булып озатырга килүчеләр эчеп, исерешеп бетсә, болай аралашып булыр идеме соң? Әлбәттә, юк. Бик кызганыч, әмма күпләр бүген армиягә озату мәҗлесләрен хәрам белән пычраталар, килгән кунакларны исергәнче эчертүне аларны хөрмәт итүгә саныйлар. Туганнар, дусларны туплаган мәҗлес күңелсез күренешкә әверелә, күпме нервы бетә, тынычлык югала, акча, байлык-нигъмәт исраф була. Нәтиҗәдә, төн йокламаган егетне якыннары сәламәтлеге какшаган, ямьсез хәлдә ерак юлга озатып җибәрәләр. Бу инде Аллаһның ачуына дучар булып, шәйтанны сөендереп чыгып китү була.

Шунысын да әйтергә кирәк: хәрамнан башланган эшнең дәвамы да, нәтиҗәсе дә хәерле, бәрәкәтле булмый. Тормыш моны гел раслап килә. Әби-бабаларыбызның элеккеге гадәтләрен, йолаларын искә төшереп, начар үрнәкләргә иярмичә, "Бисмилла"лы, догалы башлангычларны көндәлек тормышыбызга кире кайтарасы иде. Армиягә озату мәҗлесләрен дә үзебезчә - татарча, мөселманча үткәрүдән фәкать файда гына булыр иде, дип уйлыйм. Фәләховлар гаиләсендә үткән шундый мәҗлес моңа яхшы мисал булып тора.

Салаватка, хәрби хезмәткә киткән барлык якташларыбызга сау-сәламәт булып, җаваплы бурычларын лаеклы башкарырга язсын. Аллаһы Тәгалә аларны ярдәменнән ташламасын, исән-имин әйләнеп кайтуларын насыйп кылсын.

***Ришат КУРАМШИН,***
***Кукмара мәдрәсәсе мөдире***

# БӘХЕТ ЮЛЫ

**Камил шәхес тәрбияләүнең бер юлы - Аллаhның әманәтенә тугрылык. Дин аша Аллаh безне нәфсебезне тыярга өйрәтә.**



Динебезгә, асылыбызга кайту юлында республикада шактый саллы чаралар үткәрелә. Әйтик, 2012 ел - республикада Коръән елы дип игълан ителде.

Республикабызның төрле почмакларында Коръән укучылар бәйгесе уздыру матур традициягә әверелде.

Балтач мөхтәсибәтендә мондый бәйге быел дүртенче мәртәбә үткәрелде. Елның-елында анда катнашырга теләүчеләр саны да арта бара. Катнашучыларга таләпләр дә кырыслана. Бала узган ел катнашкан номинациядән югарырак баскычта көчен сынарга тиеш.

Унсигез авылдан 150 кыз, 81 малай - барысы 231 бала белемен күрсәтү, Коръән сүрәләрен тыңлау максатыннан Балтач үзәк мәчетенә җыйналды. Бу очракта "көч сынашу" мәгънәсе ирешкәннәреңне ачыклау-барлау, бүтәннәр белән чагыштыру, Аллаh ярдәменә таянып тагын ниләр эшләү мөмкинлеген ачыклау дигәнне аңлата. Хикмәт урын алуда түгел, Аллаh ризалыгын алуда. Иң мөhиме - аралашу-танышу, бер-береңнән үрнәк алу, фикердәшләр табу. Иң бәләкәй катнашучыга 3 яшь булган булса, иң өлкәненә 14-15 яшь иде.

Бәйге 5 номинациядә үтте: Коръән белән яңа таныша башлаучылар "Фатиха" (иң беренче сүрә) һәм белгән сүрәләрен яттан сөйләделәр. II баскыч - "Фил"-"Нәс (Кешеләр)", III баскыч - "Духа (Иртәнге шәфәкъ)"-"Нәс (Кешеләр)" сүрәләрен гарәпчә укып күрсәтү, IV баскыч - "Әгълә (Бөек)"-"Нәс (Кешеләр)" сүрәләрен гарәпчә укый белүдән гыйбарәт булды. V баскыч үзенчәлекле - Коръәннең бер парәсен яттан белүчеләр арасында булды.

Мине нык сокландырганы - III сыйныф укучысы Илназ Шәрәповның V номинациядә җиңүче булуы иде. Илназ өч яшьтән дини бәйгеләрдә катнаша башлый һәм елның-елында җиңүләр яулап Аллаhка якыная. Илназ мисалында мин ихтыяр көче тәрбияләү, белемле булу, вакытны бәрәкәтле һәм мәгънәле үткәрүнең, әхлакый кыйммәтләр булдыруның матур үрнәген күрәм. Ул мәктәптә дә яхшы укый икән. Андый баланың тормышта ачык максаты булып, ул кыенлыкларны җиңеп, тормышта үз урынын таба алачак. Җәмгыять чирләре, шәт, аңа йокмас. Нәни җиңүчегә бәйгенең иң затлы бүләге - сенсорлы телефон тапшырылды. (Кызлар арасында мондый зурлауга Зарипова Гөлмәрьям ия булды. Аңа 14 яшь.)

Апрель аенда Шубан авылы мәчетендә - кыз, Карадуганда ир балалар намаз уку бәйгесендә катнашты. Һәр якта 12 авылдан алтмыштан артык бала җыйналган иде. Кыз балалар намазның 16 фарызын аңлаттылар, гәүдәне дөрес тотып, хәрәкәтләрне тиешенчә башкарып намазны тәртибе белән укып күрсәттеләр. Коръән буенча дини сорауларга җавап бирделәр. Балаларның мәчеттә, өстәл янында, яшьтәшләре белән аралашканда үз-үзен тотышы, мөселманча киенүе - һәммәсе искә алынды.

Бәйгеләрнең Шубан һәм Карадуган мәчетләрендә үтүе - үзе бер куаныч. Димәк, безнең мондый зур бәйгеләрне үткәрергә матди, иҗади, дини мөмкинлекләребез бар. Имам-абыстайлар, әхлак мөгаллимнәре көчле һәм сәләтле.

Быел мәчеткә йөрүче балалар арасында Норма авылында футбол һәм хоккей ярышлары гадел хөкемнең матур үрнәкләрен күрсәтте. Балалар һәр елны Ураза, Корбан бәйрәмнәрендә бергәләп күңел ачалар. Бөрбаш авылында һәр елны үткәрелүче мөселман балалар Сабантуе, мәчетләрдә оештырылган җәйге лагерьлар да балаларның әхлаклы, иманлы, тәртипле-тәрбияле булып үсүенә уңай йогынты ясый. "Бала чакта алынган тәрбияне бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас", - дигән күренекле галимебез Ризаэддин Фәхреддин.

Иманлы балалар үстерүгә җаныбыз-тәнебез белән керешкәнбез икән, киләчәгебез, шәт, өметсез булмас.

**Әминә МӨХӘММӘТҖАНОВА,**
**Балтач районы**
**Шубан төп мәктәбенең**
**әхлак мөгаллимәсе**

# ТУФАН АГА АРАБЫЗДАН КИТТЕ



***Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте кисәк гомере өзелгән язучы, җәмәгать эшлеклесе Туфан ага Миңнуллинның якыннарының, туганнарының тирән кайгысын уртаклаша.***

Туфан Миңнуллин татар халкы өчен җан атып яшәгән һәм милләтебез өчен күп эшләр башкарган олуг шәхес иде. Туфан Габдулла улы рухи, дини-әхлакый кыйммәтләрне пропагандалаган бай әдәби мирас калдырды. Ул әсәрләре аша әдәп, иман ныклыгы, кешелеклелек кебек күркәм сыйфатларны тәрбияләргә омтылды. Туфан ага дини вәзгыятькә дә битараф булмады. Соңгы елларда төрле сәхнәләрдә аның "Мулла" пьесасы уйналды. Әлеге әсәр дин әһелләре тормышына, проблемаларга һәм динебезне саклауга аерым игътибар юнәлтте.

Киңкырлы иҗаты белән татар әдәбиятына зур өлеш керткән, иҗтимагый, мәдәни, милли проблемаларны хәл итүдә ару-талуны белми эшләгән аксакал язучыбызның арабыздан китүе - татар халкы өчен зур югалту.

Татарстан Диния нәзарәте республикабыз мөселманнары исеменнән мәрхүмнең якыннарының, туганнарының тирән кайгысын уртаклаша.

# Ничек конфликтларсыз аралашырга?

*(Ахыры. Башы газетабызның 27 апрель (№ 17) санында.)*

Моннан тыш, барлык тип очраклар өчен дә конфликтларсыз аралашуның гомуми принципларын истә тоту зарур. Аларны түбәндәгечә туплап бирергә мөмкин:

- беренчедән, бәхәс барышында тикшерену предметы кысаларыннан чыкмагыз. Ачык аңлаешлы фикердә тору, аны киң җәелдермичә генә үстерү бик тә әһәмиятле;

- икенчедән, беркайчан да әңгәмәдәшегезнең шәхси сыйфатларын тикшерүгә күчмәгез һәм оппонентыгызга үз холык-фигылегезне тикшертү адымына юл куйдырмагыз. Мисал өчен, әңгәмәдәшегез: "Син монда нәрсә аңлыйсың соң, синдә бернинди дә зәвык, ямь тойгысы юк", - дип каршы чыга икән, сез әңгәмәнең шул өлешеннән: "Без хәзергесе вакытта минем зәвык турында сүз алып бармыйбыз", - дип сөйләшүне туктатырга кирәк. Шунысын да онытмагыз, әгәр кемне дә булса бәяләүгә күчәргә телиләр икән, әңгәмәдәшегезнең уңай дәлилләре калмаган яисә ул бәхәсне, тиктомалдан, талаш-ызгышка күчерергә тели дигән сүз;

- өченчедән, тавыш тонын күтәрмәгез, тембрыгызны үзгәртмәгез, тавыш көчен арттырмагыз, үзегезне тыныч тотыгыз. Хәтта, әңгәмәдәшегез тавышын көчәйтә барган саен, сез, киресенчә, тагын да салмаграк сөйләшүгә күчегез. Бу, сезнең нәрсә сөйләвегезне аңлау өчен, үз тавыш тонын тагын да төшерүгә китерәчәк;

- дүртенчедән, әңгәмә барышында сүзгә башка кешеләрне кыстырмагыз. Бәхәскә тартылган кешеләр никадәр азрак булган саен, анда катнашучыларга бер-берсен аңлавы җиңеләя төшәчәк;

- бишенчедән, бәхәсле очракларны хәл итүдә юл куюга (компромисска) баруның кулай чишелеш түгел икәнлеген исегездән чыгармагыз. Теләсә кайсы конфликтлы очракны хәл итүнең иң яхшы рәвеше булып үзара хезмәттәшлек тора. Нәкъ менә шул сәбәп буенча әңгәмәдәшегезне мәсьәләне уртак файдага хәл итүгә юнәлтегез.

Һәм, йомгаклап, шунысын да әйтәсебез килә: бәхәскә кереп, әңгәмәдәшегез үзе уйлап куйган сценарие буенча сүз алып барачак. Бу сценарий, әлбәттә, алдан әзерләп куелган дәлилләрне һәм әңгәмәдәшенең алдан күзалланган бәясен дә үз эченә ала. Сезнең бурыч - әлеге сценарийга киңәергә ирек бирмәү. Моның өчен, иң яхшы алым булып, никадәр сәер тоелмасын, аның дәлилләренә күнү торачак. Ул, билгеле, сездән мондый адым көтмәячәк. Шул рәвешчә, ул аралашу барышында бәхәс ниятен алмаштырырга мәҗбүр булачак, аңа уйланган диалогының калган юнәлешләрен дә үзгәртү таләп ителәчәк. Шуның белән әңгәмәдәшегезнең сезгә булган дәгъвалары да бетәргә мөмкин.

Һәм соңгысы. Тагын бер нәрсәне истә тоту мәслихәт. Әгәр дә сез әңгәмәдәшегез белән дуслык халәтендә - ягымлы тонда һәм аның фикерен хөрмәт итеп - сөйләшәсез икән, аңа сезнең белән килешү психологик яктан җиңелрәк булачак.

***Нияз САБИРҖАНОВ***






## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 5.05.12 | 3:21 | 4:51 | 13:02 | 18:01 | 20:30 | 22:00 |
| Якшәмбе | 6.05.12 | 3:19 | 4:49 | 13:02 | 18:02 | 20:32 | 22:02 |
| Дүшәмбе | 7.05.12 | 3:17 | 4:47 | 13:02 | 18:03 | 20:34 | 22:04 |
| Сишәмбе | 8.05.12 | 3:15 | 4:45 | 13:02 | 18:05 | 20:36 | 22:06 |
| Чәршәмбе | 9.05.12 | 3:13 | 4:43 | 13:02 | 18:06 | 20:38 | 22:08 |
| Пәнҗешәмбе | 10.05.12 | 3:11 | 4:41 | 13:02 | 18:07 | 20:40 | 22:10 |
| Җомга | 11.05.12 | 3:09 | 4:39 | 13:02 | 18:09 | 20:42 | 22:12 |
| Шимбә | 12.05.12 | 3:07 | 4:37 | 13:02 | 18:10 | 20:44 | 22:14 |





**ООО «Ритуальные услуги»**
**Изготовление памятников и оград**

ул. К.Насыри, 17, мечеть Аль-Марджани,
ул. 2-я Армавирская мечеть Нур-эль-Ислам,
ул. Мусина, 10, мечеть Булгар,
ул. Чистопольская, 1, мечеть Казан Нуры,
Оренбургский тракт, 193, мечеть Гадель,
ул. Мавлютова, 48, мечеть Ризван,
ул. Фучика, 52, мечеть Хузейфа,

Понедельник - пятница -
с 9:00 до 18:00,
суббота - с 9:00 до 13:00.
**Тел.: 225-28-90, 293-25-61**

Основное производство находится на мусульманском кладбище при мечети Аль-Марджани на Мамадышском тракте.
Понедельник - с 9:00 до 13:00, со среды по воскресенье - с 9:00 до 18:00,
вторник - выходной.
**Тел.: 8-927-427-16-02, 293-45-93**

**На мусульманском кладбище захоронения ведутся по канонам Шариата.**
**Тел. 297-28-90**



**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №18 (135) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-532.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 4 май көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).


**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга куллланудан сакланыгыз!**